

Сентябрьнен беренче декадасында Россиядә финансистлар конен-финанс олкәсендә эшләvче барлык хезмәткәрләрнен; акыллы, белемле, жаваплы кешеләрнен бәйрәме. Шул кон-не Кадошкино районнын тотрыклылыгы да профессиональлегенә, тогәллегенә һәм ныклыгына бәйле кешеләр турында сойләнде. Сvз алар турында “Возрождение” дигән район газетасында иде.      Безнен һәркайсыбыз теләсә кайсы бәйрәм яки тантаналы чара, биналар, социаль объектлар һәм юллар тозv, учреждениеләр, оешмалар, предприятиеләрнен эшчәнлеге һәм vсеше артыннан кvренмәс фронт кешеләре торуы турында уйланабыз. Коннән-кон финанс стратегияләрен эшләvчеләр, момкин булган барлык куркынычларны исәплиләр, акча агымнары һәм киләчәк табышлары белән идарә итәләр. Кадошкино поселогынын, районынын финанс артериясенә “кул тотучылар” алар, финансистлар. Кем белә: акчаны дорес итеп экономияләvме жинелме, әллә аларны сарыф итv тагын да катлаулыракмы?..

Бvген район хакимиятенен финанс идаресендә алты кеше эшли. Аларнын һәркайсы, һичшиксез, аерым матур сvзләргә лаек, ләкин очраклы кешеләр булмаган чын команда булганда, нәкъ менә бердәм коллектив турында әйтәсе килә. Алар хезмәттә - vз эшенен профессиональлары, намус белән  нәтижәле эшләvче белгечләр, ә тормышта - гади сойкемле хатын-кызлар. Коллективы турындагы фикерне житәкчесе әйтә: “Барлык белгечләр дә белемле, жаваплы, игътибарлы, интеллектуаль, - дип горурланып билгеләп vтә район башлыгы урынбасары - финанс идарәсе начальнигы Надия Руслан кызы Уторова (фотода алга утырган). - Идарәнен ин яшь белгече Любовь Владимировна Лапшина (фотода сулдан икенче). Ул нибары ике ел эшли, әмма бу вакыт эчендә vзен квалификацияле хезмәткәр буларак кvрсәтеп олгерде инде. Любовь Владимировна vзенен хезмәт вазыйфаларын vтәv очен кирәкле белемгә ия, инициативалы, һәр-вакыт камилләштерергә омтыла, эшне жиренә житкереп башкара, vз фикерен яклый белә. Анын вазифасына биш авыл жирлеге бюджет чараларын финанслау һәм аларнын vтәлешен контрольдә тоту керә. Моннан тыш, Любовь Лапшина ме-нә дигән хужабикә һәм ике кызнын әнисе. Кече кызы - Тая, балалар бакчасына йори, ә олысы - Лиза, унынчы сыйныфта укый.

Финанс ида-рәсе начальнигы урынбасары, баш хисапчы Наталья Викторовна Камышова (фотода сулдан оченче), баш белгеч Наталья Юрьевна Захарова (фотода сулдан дvртен-че), консультантлар Светлана Әмин кызы Байчурина (фотода сулдан беренче), Альбина Әнвәр кызы Поташова (фотода юк), Любовь Владимировна Лапшина - районнын финанс системасы әнә шулай тырыш, vткен, аналитик акыллы кешеләрнен исемнәре белән бәйле”, - дип сvзен йомгаклады Надия Руслан кызы Уторова.

“Яхшы финансист - ул нинди финансист?”- дип кызыксындык финанс идарәсе начальнигы Надия Руслановнадан.
Жавап кичекмәстән шундый булды: “Грамоталы, гадел, тәртипле”.
Әгәр дә бу сыйфатлар житәкче очен остенлекле икән, Кадошкино районы финансчылары коллективында нәкъ менә шундый кешеләр эшләвенә шик юк.

**Наилә НАСЫРОВА**
**әзерләде**